| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2025 г. Казань № 1-1/соц-2025

Татарстан Республикасында «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 21.12.2024 ел,ел, № 1180, «2025-2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 13.02.2021 ел, № 77, «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә җан башына исәпләнгән финанслау нормативы турында» 30.12.2024 ел, № 1276 карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 29.01.2025 ел, № 1 беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән алып 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.01.2025 № 1-1/соц-2025
карарына кушымта

«Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтү | сум/сәгать | 377,40 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге